# *Габдулла Тукай (1886-1913).*



- Мөхәммәтгариф углы Габдулла Тукай 122 ел элек 1886 елны апрельнең 26-да Казан артындагы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Биш ай чагында аның әтисе, ә 4 яшьлек чакта әнисе дә үлеп китә. Габдулла Тукай кече яшьтән дөм ятим калып, кулдан кулга күчеп йөрү михнәтләрен күргән. Тукай тормышын өч чорга бүлеп була: беренчесе – Кырлай, икенчесе – Уральск, өченчесе – Казан чоры.



# Тукай нәселенең шәҗәрәсе



# Балачагы





**Кушлавычта, Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә 1886 елның 26 (14) апрелендә бер ир бала – булачак шагыйрь Габдулла Тукай дөньяга килә.**


ТУКАЙНЫҢ СӘЯХӘТЛӘРЕ
Петербург 1912
Троицк 1912
Гурьевка
Кушлавыч 1886
Кырлай 1892 – 95
Нижний Новгород 1908
Өчиле 1911
Казан 1890 – 1892 1907 – 1913
Уфа 1912
Уральск 1895 – 1907
Астрахань 1911

- ***Кырлайда*** ***Сәгъди абзый йортында үткән берничә ел яшь Габдуллага крестьян тормышының авырлыгын һәм матурлыгын аңлау юлында беренче тәҗрибәне биргән. Сәгъди абзый Тукайны эшкә өйрәтте һәм хезмәт иясенә хөрмәт тәрбияләде. Кырлайда Габдулла укырга йөри башлый. Кырлай мәдрәсәсендә булачак шагыйрьнең белем нигезе салына. Кырлайда туган беренче уй-тойгылар Тукай поэзиясенең күп кенә илһамлы юллары, темалары булып китүе дә мәгълүм. “Шүрәле” әкияте үзе генә дә Кырлай истәлегенең гүзәл бер шигъри һәйкәле итеп санала. “Пар ат” һәм “Туган җиремә” кебек шигырьЛәре дә Кырлай истәлекләре белән рухланган.***

Кечкенә Апуш Сәгъди абзый белән



Кырлайда Сәгъди абзый йорты



- **1895 елда Габдулла Тукай Уральскига атасының сеңелесе Газизә Забирова тәрбиясенә алына. Шунда ул мәдрәсәгә укырга керә. “Мотыйгыя” мәдрәсәсендә башкалардагы кебек вактөяк кысынкылыклар булмаган. Анда шәкертләргә өлешчә ирек бирелгән. Шуның өстенә, 20-нче йөз ахырларында Рәсәйдә мәгърифәтчелек һәм яңача укыту хәрәкәтләре көчәя. Булачак шагыйрь Габдуллага шушы шартлар иҗатын ачылуга ярдәм итәләр.**

- 1905 елгы революция Уральск шәһәрен дә тетрәтте. “Фикер”, “Әлгасрел-җәдит”, “Уклар” исемле беренче татар телендә гәҗитә һәм журналлар чыга башлый. Тукай шул басмаларда хәреф җыючы, төзәтүче, хәбәр җыючы, хәтта мөхәррир булып та эшләде. Бигрәктә татар телендәберенче юмористик һәм сатирик басма булган “Уклар” журналын ул тулысынча әзерләп һәм редакцияләп килә, аның үрнәгендә Ту... матбугатның ни... ...н күрсәтергә тели.



- 1907 елның көзендә Габдулла Тукай туган якларына кайта һәм Казанга килеп урнаша: “Әл - ислах” исемле журналда һәм “Китап” нәшриятында җиң сызганып эшләүчеләрдән берсе булып китә.
- Тукай – кыска гына вакыт эчендә шигъри осталык югарылыгына, сүз сәнгате серләрен ачуга ирешкән шагыйрьләрнең берсе. Аның поэзиясендә өч зур эстетик гореф-гадәт бергә очрашты: болар бик борынгыдан килә торган төрки поэзия,



- **Тукайны халыкның тормышы, зыялыларның тәртибе борчый, ил эчендә һәм тышында булган күп кенә әһәмиятле вакыйгалар, хәлләр аның игътибарын җәлеп итә.**
- **Казанга килгәннән бирле беркая чыкмый яшәгән шагыйрь, сәламәтлегенең гаять начарлануына карамастан, 1911-1912 елларда берничә тапкыр сәяхәткә батырчылык итә: Идел буйларындагы тормыш белән таныша, Уфа, Петербург тарафларына юл тота...**



Габдулла Тукай Санкт-Петербургта.1912ел.

- *Шагыйрьнең саулыгы көннән-көн начарлана бара. 1913 елның апрельнең 15-дә 27 яшендә Габдулла Тукай якты дөньядан мәңгелеккә күчә. Никадәр генә газаплар кичерсә дә, бу фаҗигале, кыска гомер юлын горур атлап уза*





Кырлайда Габдулла Тукайның мемориаль музееның яңа бинасы



Казанда Габдулла Тукай һәйкәле



Кырлайда Габдулла Тукай һәйкәле      Казанда Габдулла Тукай музее






# Габдулла Тукай премиясе лауреатларына бирелә торган медаль









# Китаплары











Шүрәле



Су анасы




Кызыклы шәкерт



Бишек җыры



- «3 нче номерлы Аксубай гомуми урта белем бирү мәктәбе” Аксубай муниципаль районы Татарстан Республикасы

Төзеде:
Закирова Албина 6В сыйныф укучысы
Җитәкче :
Багаутдинова Н.С.